СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**03 февраль 2025 ел** **№ 124**

## «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" карар проекты хакында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендә 173 номерлы карары белән кабул ителгән (Советның 06.08.2020 ел 225 номерлы, 19.01.2021 ел 24 номерлы, 19.08.2022 ел 60 номерлы, 14.12.2023 ел 91 номерлы карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставын федераль һәм региональ кануннарга яраклаштыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 маддәләренә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 7, 20 маддәләренә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Карары проектын нигез итеп кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча оештыру комитетын (алга таба – оештыру комитеты) түбәндәге составта төзергә:

1) Гарифуллина З.Р. – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы, оештыру комитеты рәисе;

2) Галимзянов Р.Г. - Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутаты - оештыру комитеты рәисе урынбасары;

3) Фокеев И.Н. – Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутаты - оештыру комитеты әгъзасы.

4. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Карары проекты буенча гавами тыңлауларны 25.02.2025 ел көнне сәг. 13.00 дә Татарстан Республикасы Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча билгеләргә.

5. Гавами тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитетына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне, исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Совет Рәисе, Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы З.Р.Гарифуллина

1 нче кушымта
Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 03.02.2025 № 124 карарына

**СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

Тел./факс: +7(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**________________2025 г.** **№ _____**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 207 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләр Уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 13 декабрендәге 207 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 06.08.2020 №225, 19.01.2021 №24, 19.08.2022 № 60, 14.12.2023 №91 карарлары редакциясенә), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 статьяның 2 пунктында «, кыскартылган исеме – "Алан-Бәксәр авыл җирлеге» сүзләрен өстәргә;

2) 6 статьяның 1 пунктында:

а) 12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, авыл җирлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру

мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 21 пунктча өстәргә:

"21) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

3) 20 статьяның 5 пунктындагы 2 абзацында «1-7 пунктларында» сүзләрен «1-7 һәм 9.2 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга.;

4) 32 статьяның 14 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

5) 35 статьяның 1 пунктындагы 26 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, рәсми мәгълүматны муниципаль берәмлек халкына җиткерү өчен матбугат массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын булдыру;»;

6) 35 статьяның 1 пунктындагы 33, 39 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

7) 42 статьяда:

а) 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 13 пунктча өстәргә:

«13) затның чит ил агенты статусын алуы;»

б) 13нче пунктчаны 14нче пунктча дип санарга;

8) 48 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 18 пунктча өстәргә:

"18) затның чит ил агенты статусын алуы.»;

9) 51 статьяның 8 пунктчасының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, авыл җирлегендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

10) 58 статьяның 3 пунктында "Җирлек сайлау комиссиясенең," сүзләрен төшереп калдырырга;

11) 59 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

"12) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетадагы белешмәләрдә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) билгеле булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба – анкетада күрсәтелгән белешмәләр);

12) 60 статьяның 2 пунктында ", Җирлек сайлау комиссиясенең» һәм «Җирлек сайлау комиссиясе аппаратының" сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 81 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«81 статья "Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе"

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр алар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән Килешүне рәсми рәвештә халыкка җиткерү булыптора:

1) Тулы текстны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС77-60244, Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 17.12.2014 елда бирелгән), яисә «Биектау хәбәрләре» газетасында (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС 77-47612 Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан 07.12.2011 елда бирелгән) рәсми бастырып чыгару;

2) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру.

3. Гражданнарның Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына керүен тәэмин итү өчен түбәндәге адреслар буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: 422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 (авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы).

4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләрне үз эченә алган муниципаль хокукый актлардан яисә аларның аерым нигезләмәләреннән тыш, аларга кул куелган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелә.

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

6. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга имза салынган көннән үз көченә керә.

7. Муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган вакытлы матбугат басмаларының, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәрен һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы белешмәләр күрсәтелгән, вакытлы матбугат басмаларының, челтәр басмаларының исемлеге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерелә.

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәве алганнан соң, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы                                                                                    З.Р.Гарифуллина

2 нче кушымта
Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районының
Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Советы 03.02.2025 № 124
карары белән

**ТӘРТИП**
**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе**

1. Әлеге «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм аның буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе» (алга таба – тәртип) Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 4 пункты нигезендә гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертү тәртибен беркетә.

2. Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге халкы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проектны халыкка җиткергәннән соң аның турында фикер алышуда түбәндәге рәвешләрдә катнашырга хокуклы:

1) яшәү урыны буенча гражданнар җыелышларын үткәрү;

2) әлеге Тәртип нигезендә Устав проекты буенча массакүләм фикер алышу;

3) Устав проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру;

4) гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә.

3. Тәкъдимнәр Алан-Бәксәр авыл җирлегенә түбәндәге адрес буенча бирелә: 422723, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19, телефон 8(84365)63951.

3. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәр гражданнар өчен - фамилия, исем, атасының исеме, яшәү урыны күрсәтелеп имзаланырга, юридик затлар, иҗтимагый оешмалар, берләшмәләр өчен - адресы, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелеп, мөһер сугылып имзаланырга тиеш.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында бастырып чыгарылган проект буенча халык тарафыннан гавами тыңлауларда күрсәтелгән өстәмәләр һәм (яисә) үзгәрешләр турындагы тәкъдимнәр (алга таба – тәкъдимнәр) гавами тыңлауларның йомгаклау документында күрсәтелә, ул Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча Оештыру комитетына тапшырыла (алга таба – эшче төркем).

5. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) проектка халыкның тәкъдимнәре ул басылып чыккан көннән алып 20 көн эчендә эшче төркемгә кертелергә һәм әлеге Тәртип нигезендә каралырга мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәр Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә яшәүче, актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан кертелергә мөмкин.

7. Граждан (гражданнар төркеме) Устав проекты буенча тәкъдимнәрне кушымта нигезендә, әлеге Тәртипкә нигезләнеп рәсмиләштерә һәм аларны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу буенча эшче төркемгә җибәрә.

8. Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы депутатлары Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Регламентында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проект буенча тәкъдимнәр кертәләр.

9. Кертелгән тәкъдимнәр эшче төркем тарафыннан теркәлә.

10. Тәкъдимнәр Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон таләпләренә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына туры килергә тиеш.

11. Тәкъдимнәр түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

1) Устав проекты нигезләмәләренә бер мәгънәле аңлатма бирергә тиеш;

2) устав проектының башка нигезләмәләре белән каршылыкка йә килешмәүгә юл куймаска.

12. Әлеге тәртиптә каралган таләпләрне һәм срокларны бозып кертелгән тәкъдимнәр караусыз калдырылырга мөмкин.

13. Кертелгән тәкъдимнәрне өйрәнү, анализлау һәм гомумиләштерү нәтиҗәләре буенча эшче төркем йомгаклау төзи.

14. Кертелгән тәкъдимнәргә эшче төркем Бәяләмәсендә түбәндәге нигезләмәләр булырга тиеш:

1) кергән тәкъдимнәрнең гомуми саны;

2) әлеге Тәртип нигезендә каралмыйча калдырылган кергән тәкъдимнәр саны;

3) әлеге тәртиптә куела торган таләпләргә туры килмәү сәбәпле кире кагылган тәкъдимнәр;

4) эшче төркем тарафыннан кире кагуга тәкъдим ителә торган тәкъдимнәр;

5) Устав проекты текстына кертү өчен эшче төркем тарафыннан тәкъдим ителә торган тәкъдимнәр.

15. Эшче төркем үзенең бәяләмәсен һәм эшче төркем эшчәнлеге материалларын, кергән барлык тәкъдимнәрне дә кушып, Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советына тапшыра.

16. Тәкъдимнәрне кабул итү (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында проект текстына кертү) яисә кире кагу турындагы мәсьәләне хәл итәр алдыннан Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге советы эшче төркем

җитәкчесенең яисә эшче төркемнең вәкаләтле әгъзасының эшче төркем эшчәнлеге турында докладын тыңлый.

17. Устав проекты буенча гражданнардан кергән тәкъдимнәрне карау йомгаклары халыкка җиткерелергә тиеш.

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының
Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү
турында гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм фикер алышуда катнашу
тәртибенә

**Тәкъдим**
**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына гражданнар тарафыннан аның турында фикер алышканда кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы проект буенча**

| № | Пункт, пунктча, статья | Устав проекты тексты | Төзәтмә тексты | Устав проекты тексты (төзәтмәләрне исәпкә алып) | Төзәтмә кертүче |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**Мәгълүмат**
**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында проект буенча тәкъдимнәр керткән граждан (гражданнар төркеме) турында**

| | |
|---|---|
| Тәкъдим керткән гражданның (гражданнарның) фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| Өй адресы, телефон | |
| Шәхесне таныклаучы документ турында мәгълүматлар | |
| Эш, уку урыны | |

Гражданның (гражданнарның) имзасы Дата